# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**14 ноябрь 2020 ел** **№ 1**

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Мәнәвез авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Уставы нигезендә 2020 елның 14 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез, 2021 елда 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Мәнәвез авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:
- мини-футбол буенча спорт мәйданчыгы урнаштыру (коймалау өчен материал, футбол капкалары ясау өчен материал алу, спорт инвентаре сатып алу);
- Мәнәвез авылы мөселман зиратында контейнер мәйданчыклары урнаштыру (коймалау өчен материал алу, коймаларны ясау һәм урнаштыру, җирлеген ясау,;
- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк, сувенир продукция сатып алу, «Җиңү көне», «Халыкара өлкәннәр көне», «Корбан бәйрәме», «Яңа ел " бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү»);
- җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (авыл мәдәният йорты, ФАП, балалар бакчасы янындагы территориягә таш түшәү (ташны сатып алу, ташу, тигезләү));
- трактор йөртүчесенә хезмәте өчен түләү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 481 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 303.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 287, «КАРШЫ» позициясе өчен 16 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Мәнәвез торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре–гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәнәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез, 2021 елда 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Әгерҗе авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:
- мини-футбол буенча спорт мәйданчыгы урнаштыру (коймалау өчен материал, футбол капкалары ясау өчен материал алу, спорт инвентаре сатып алу);
- Мәнәвез авылы мөселман зиратында контейнер мәйданчыклары урнаштыру (коймалау өчен материал алу, коймаларны ясау һәм урнаштыру, җирлеген ясау,;
- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк, сувенир продукция сатып алу, «Җиңү көне», «Халыкара өлкәннәр көне», «Корбан бәйрәме», «Яңа ел " бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү»);
- җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (авыл мәдәният йорты, ФАП, балалар бакчасы янындагы территориягә таш түшәү (ташны сатып алу, ташу, тигезләү));
- трактор йөртүчесенә хезмәте өчен түләү.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә
- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,
- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru),
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Мәнәвез авылы, Советская урамы, 1а адресы буенча, Мәнәвез авылы, Советская урамы, 29 йорт каршында, Мәнәвез авылы, Узәк урамы, 60 йорт каршында урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Әгерҗе авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Хәсәнов